ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 март 2022 ел № 1452

Башкарма комитетның «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе субъектларының дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 декабрендәге 8500 номерлы карарын гамәлдән чыгару хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.20, 5.23 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2022 елның 12 гыйнварында «Челнинские известия» газетасының 1 санында, 2022 елның 12 гыйнварында «Шәһри Чаллы» газетасының 1 санында бастырып чыгарылган «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе субъектларының дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 декабрендәге 8500 номерлы Башкарма комитет карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов